**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

12.09.2022 796-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 22 ноябрендәге 1284-п номерлы боерыгы белән расланган Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын ачу фактын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 22 ноябрендәге 1284-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 22 июнендәге 524-п номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын ачу фактын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып җир асты байлыкларыннан файдаланучылар – Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән юридик затлар, җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирелгән Россия Федерациясе гражданнары булган шәхси эшкуарлар (алга таба –мөрәҗәгать итүче) тора.»;

2 бүлектә:

2.6.1 пунктының өченче абзацын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«а) мөрәҗәгать итүче турында белешмәләр, шул исәптән юридик зат өчен – тулы атамасы, аның оешу-хокук формасы, электрон почта адресы (булган очракта), почта адресы, төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры, шәхси эшкуар өчен – фамилия, исем, ата исеме (булган очракта),

электрон почта адресы (булган очракта), почта адресы, шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номерының аның «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законы) 9 статьясы нигезендә җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга карата җир асты байлыклары турында Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган аналогы;»;

2.6.1 пунктының дүртенче абзацын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«б) гомумтаралган файдалы казылмалар ятмасын ачу фактын билгеләгәндә җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирүгә гариза бирү хокукына ия булган зат турында белешмәләр, шул исәптән юридик зат өчен – тулы исеме, аның оешу-хокук формасы, электрон почта адресы (булган очракта), почта адресы, төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры, шәхси эшкуар өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), электрон почта адресы (булган очракта), шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры.»;

2.6.2 пунктының икенче абзацын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1) таныклык тапшырылган зат турында белешмәләр, шул исәптән юридик зат өчен – тулы исеме, аның оешу-хокук рәвеше, электрон почта адресы (булган очракта), почта адресы, төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры, шәхси эшкуар өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), электрон почта адресы (булган очракта), почта адресы, шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүченең тәңгәллек номеры;»;

2.6.5 пунктының унынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары И.И.Гобәйдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков